**Айдар ХӘЛИМ**

# ӘҮЛИЯЛӘР ГАЛӘМЕНДӘ

Ул үзенең кечкенә булса да тос кына шигырьләр китабын «Хәмит Латыйпов» дип чыгарган. Мин исә, үзеннән дә сорамыйча, «ов»ын алып ташлап, аны «Хәмит Латыйп» дип кенә атарга булдым. Үпкәләмәс әле. Ни дисәң дә, бу йот кыргыры империя, аны «ов»лар белән күпме генә ашатмадык, барыбер туймады. Дөрес, бездә моңа кадәр Латыйплар нәселеннән ике бик шәп шагыйрь билгеле иде: Галимжан Латыйп һәм Кави Латыйп. Әйдә, өчәү булсыннар. Бу нәсел безгә бары тик яхшы шагыйрьләр генә бирә бит.

Хәмит Латыйп шагыйрь һәм рәссам, рәссам һәм шагыйрь. Бу дөньяны ул рәссам буларак ачса да, аңарда кайсысы беренчел – әйтүе кыен. Нигә, бу шул кадәре мөһим нәрсә мени? Шагыйрь дә шул ук рәссам бит инде. Тик ул күбрәк жир һәм күк, йолдызлар белән эш итә. Хәмит шигырьләрен чагыштырмача күптән түгел иҗат итә башласа да, ул бит гомере буе шагыйрь булган, шулай бит? Әгәр ул тумыштан шагыйрь булмаса, коргаксып кипкән йолдызлар кебек шыңгырап торган шигырьләрен каян алыр иде?

Кушылып кошларга,
Теләдем очарга,
Моңланып җырларда
Юл алдым кояшлы кырларга.
Гомерем уңышлы –
Күкрәгем атылган йолдызлар куышы,
Атылган йолдызлар куышы.
Күңелем тулышты,
Җан белә мәңгелек булмышны.

Нинди матур куркыныч, нинди бөек куркыныч шигырь! Мондый шигырьләрне гомер буе йөртү өчен адәм баласына никадәр түзем һәм батырлык кирәк! Татардагы барлык атылган йолдызлар – йөрәкләрне сыйдырыр өчен бу адәм баласында нинди күкрәк куышы булырга тиеш?! Анысын инде ул үзе генә белә. Шуңа күрә аның гомере – мизгелгә, әйтергә ашыгуы – ашыкмауга, хәрәкәте – тын торуга тиң. Шуна күрә ул шигьри юллары артыннан тыныш билгеләре куеп азапланмый. Нәкъ җырдагыча – «билгеле бит инде болай да...»

Хәмит Латыйп кайчандыр район үзәге, хәзер инде зур шәһәр булып житешкән Туймазы шәһәрендә яши. Тарихта Урал алды, Уфа татарлары буларак билгеле алар. Әле һунн бабаларыбыз заманнарыннан Урал алды һәм Урал арты, Агыйдел, Ашказар буйларында яшәгән безнең бөек кавемебез. Шагыйрь үзе әйтмешли, «әүлияләр төбәге». 1922 елда Сталин бу төбәктәге ике миллион чамасы татарны, халыкның үзе белән кинәшми-нитми, «референдумны

соңрак үткәрербез» дип кечкенә Башкортстанга бүләк итә һәм Казанга кушылырга теләгән бу төбәк менә сиксән елга якын инде илсезлек касафатында изелә. Бу тойгы аның шигырьләрендә кара карлыган карасы пропискасында, җаны белән исә Казанда ул. Кайда татар, шунда аның йөрәге. Нindидер кара көчләр әүлияләр төбәген бүлгәләгән, бер милләт исәбеннән ясалма халыклар, ясалма илләр кораш-тырган, хәзер инде алар, көчәеп алып, «эт симерсә, хуҗасын талый» дигәндәй, аналарын талый...

Карлар ява дулый-дулый,
Дала ап-ак карга күмелә.
Җан ачысы белән аваз килә
Әүлияләр шулай тилмерә.
Әүлияләр авазына таба
Оч авазым көч бир аларга.
Галәм белән галәм якынайсын
Салкын упкын бетсен арада.

Хәмит кардәшебез, күрүебез-сизүебезчә, үзе дә әүлияләр нәселеннән. Сабый чактан ук ятимлеккә дучар булып, сабый әүлия өлкән әүлияләр даирә көч-куәт алган. Шуңа күрә аның һәр шигъри юлында, хәтта шигырьләреннән исемендә дә көч-куәт, нindидер әүлиялек бәреп тора: «Таң алды», «Иртәнге хәрәкәт», «Аңлы дөнья», «Галәм көе», «Алиһәләр йөзе чагыла галәмнәрдән», «Мәңгелек һәм аклык», «Төнге әйдәү», «Җан һәм җиһан», «Җир һәм күк».

Күңелнең пәрдәсен нурладың –
Әллә син Ходаем кошымы.
Идәнгә очканын юрганның
Сизмәдем – җан Күккә кушылды.

Илаһи мизгел! Әүлияләр нәселеннән булган ошбу туганыбыз Туймазыда, «ни бары Туймазыда, җанының сөекле «сөргенендә» яши. Бер яктан - Мәскәү, икенче яктан башкортка әйләнгән татар Уфасы басымында яши ул. Бу басымның нинди икәнен Актаныш һәм Мөслим, Казан һәм Норлат белми. Шуна күрә «кысылмый», «алдыйсыздыр» ди. Ә басым зур. Кая барма, еланнар, сатлык җаннар оясы бит. Лаокоон сыман еланнарны өзгәләгәндә, басым тагын да күтәрелә. Басым үлчәгечегез булса, үлчәп карагыз:

Кагылган-сугылган җанымны
Кайларга алыплар барасы.
Яфраклар түшәлгән юлларга
Капланмый ничекләр каласы.
Яфраклар түшәлгән юлларга
Тоташкан гомерем юллары.
Ак җаным мин сине саргайтмый
Яшәргә тырыштым – булмады.

Яфраклар түшәлгән юлларга,
Капланмый ничекләр чыдаем.
Инәлгән җанымны тыңлар да
Ярлыкар Ходаем.

Хәмит энекәшебез буяулар белән мул эш итә. Ул аларны кызгана белми. Мин рәссам түгел, әйтә алмыйм, буяулар белән артык эш итү сурәт сәнгатендә ничек бәяләнәдер. Шигърияттә исә мондый иркенлек нәкъ таманча дигән сүз. Мондый артып калу, арттан коелып калу да таманча дигән сүз. Ул кеше өлешенә керми. Бурычка да алмый. Ул шигырен беркайчан да утырып язмыйдыр кебек. Ул бары тик рәнҗи, йә куана. Шушы ике тойгы аның күкрәген «атылган йолдызлар белән тутыра». Шуннан – мизгел дә килә! – яшьтә пылт итеп күздән шыта. Шигырь туа, димәк. Шуңа күрә андый шигырь «бербөтен сурәт» була да куя:

Печәнлектә таллык курасы,
Күбәләрдән әкият бурасы.
Үләннәргә төшкән чыклар кебек,
Күк йөзендә йолдыз урдасы.
Урманнары күккә үрелгән,
Йолдызлар да инде сүрелгән.
Кара күләгәләр таң нурында,
Өй түбәләренә үрелгән.

Хәмит Латыйп әле сиксәненче еллар башында Уфада яшь татар рәссамнарының атаклы Наил Латфуллиннар җитәкчелендә оешкан «Алтын Урда» кебек сәнгатькярлар студиясе белән берлектә иҗат иткән. «Жир һәм Күк» дип аталган һәм изге җанлы егетләребез ярдәмендә Туймазыда ук чыккан! – китабын ул үзенең сурәтләре белән бизәгән. Гади гәзит кәгазендә, бары тик аклы-кара буяуларда гына да тетрәтә алар кешене. Сурәтләр белән бергә шигырь дә тетрәтә. «Их, – дип куясың мондый мизгелдә, – күрсәтергә иде мондый егетләребезне япун кәгазендә, Европа полиграфиясендә!» Әмма, ни кызганыч, әлегә андыйларга «суык кояш», әлегә андыйларга «караңгылык җанда». Шагыйрь үрсәләнә. Гомер үтә, Ходай Тәгаләдән килгән байлыклар бушка әләф-тәләф ителә. «Яратканы бер кыз булды, ә ул кочалмады, күңелендә яралды моң, тыңлап туялмады». Ул күк гөмбәзен дер селкетә башлый. Ул үзенә аваздаш эзли. Таба алмый җәфалана. Микеланджелолар заманыннан, дөнья яралганнан алып килә торган Лаокоон көрәше. Күрәсең, шулай булган, шулай булачак. Бездә, Рәсәйдә, ул инде аеруча. Чөнки империя уставы бары тик көчләү һәм бәхетсезлек исәбенә яшәүгә генә исәпләнгән.

Кер төшерми алып барыйм
Ак җанымны сиңа.
Кансызлыклар һаман буа
Салкын кереп тулган җанга.
Җаным туңа.

Ә без шагыйрьнең нинди шигырьләрен укып җылынабыз! Ул үзе туңган, әмма безне җылыта. Сәнгатьнең кансыз закуны шушы мәллә, Ходаем?! Кем китереп җиткергән безгә бу шигырьләрне? Нәрсә, дөньяда бер генә дә миһербанлы кеше калмаган мәллә?!

Юк, юк, Аллага шөкер, бар. Татар дөньясы бөтенләй саекмаган әле. Моннан ике ел элек «Аргамак» журналы редакциясе Хәмит Латыйпның шигырьләрен бик кадерләп беренче тапкыр дөньяга күрсәтте: бәхетенә каршы, шигырьләр кульязмасы игелекле редакторлар кулына эләкте. Аннан Хәмитнең фикердәшләре Казанда аның кечкенә булса да күргәзмәсен оештырдылар. Алдарак тагын оештырачаклар дип беләбез. Туймазыдагы дуслары акчасын юнәтеп, әйткәнемчә, шул ук Туймазыда аның әле без танышып чыккан беренче китабы нәшер иттеләр. Бу китаптагы шигырьләрнең барысын да Хәбил Нажар, мөхәррир буларак, басуга әзерләгән, китап рәвешенә китергән һәм аңа «Әүлияләр мизгеле» дигән сүз башы да язган иде.

Миңа калса, бу шигъриятkә хәлемнән килгәнчә бәя бирүдә катнаша алуыма куанам.

Хәмит Латыйпка илле диләр. Аның кебек чын егет кешегә бу әле чын иҗатның башы гына.

Меңләгән укучылары, күргәзмә залларындагы тамашачылары исеменнән мин Хәмит энекәшемне олуг бәйрәме белән котлыйм һәм якты офыкларга каравын телим.

Офыклар якты булачак. Караңгылык, ничек кенә катлы-катлы булмасын, мәңгелек була алмый.

*Айдар Хәлим. 04.02.99. Чаллы.*

*// Аргамак. – 1999. – № 4.*